**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22 АВГ 2014 № 01-02/323

г. Казань

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ
ТЕРКӘЛДЕ
МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ЗАРЕГИСТРИРОВАНО
"05" 09. 2014 г.
ТЕРЧ №
РЕГИСТРАЦИОННЫЙ 2418

"Иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында
күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен,
шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы
актуаль проблемаларга кагылышлы
җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен
Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре территориясендә
махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның
исемлеген раслау турында"
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының
2013 елның 6 августындагы
№ 01-02/59 боерыгына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәренең иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен Татарстан Республикасы Ютазы районы территориясендә махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы № 01-02/59 боерыгы белән расланган исемлегенә өстәмә турындагы тәкъдимен исәпкә алып,

**Б О Е Р Ы К Б И Р Ә М:**

1. Иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре территориясендә махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы № 01-02/59 боерыгы белән расланган исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 4-6 пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Чаллы шәһәре | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Шишкин бульвары, 29/04 | Шишкин күчеше белән янәшә Шишкин бульварындагы 29/01нче йорт янындагы территория |
| 5. | Чаллы шәһәре | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Ш. Усманов ур., 50/06 | Боровецкого бульвары белән янәшә Ш. Усманов урамындагы 50/06 нчы йорт янындагы территория |
| 6. | Чаллы шәһәре | Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Низаметдинов ур., 29 | Низаметдинов урамындагы 29 нчы йорт янындагы территория». |

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Слепнева Э.И.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга тиеш.

3. Закон проекты эше бүлеге (Пашкова М.А.) әлеге боерыкның татар теленә тәрҗемәсен тәэмин итәргә тиеш.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге (Сафин А.Г.), Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Слепнева Э.И.) белән берлектә, әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рус һәм татар телләрендә урнаштыруны (бастырып чыгаруны) тәэмин итәргә тиеш.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова